ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2019 № 136

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль район башлыгы стипендиатларын билгеләү турында»гы 2014 елның 04 июлендәге 757 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Бөтенроссия ярышларында югары нәтиҗәләргә ирешкән Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына адреслы ярдәм күрсәтү максатыннан һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарында кадрлар үзгәрешләре белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларын Алабуга муниципаль район башлыгы стипендиатларын билгеләү турында»гы 2014 елның 04 июлендәге 757 санлы карарына үзгәрешләр кертергә:

   1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы башлыгы стипендиясен бирү комиссиясе составын яңа редакциядә Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларын Алабуга муниципаль район башлыгы стипендиатларын билгеләү турында»гы 2014 елның 04 июлендәге 757 санлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы башлыгы стипендиясен бирү турындагы Нигезләмәнең 5 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

3. Бирелгән карар масса-күләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә бастырылырга тиешле.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин